| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2017 Казан ш. № 6-186/тп

«Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәренә газдан файдалану җайланмасын технологик ялгау өчен 2018 елга түләү билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бәяләрен, аны транспортлаштыру хезмәтләренә тарифларны һәм газдан файдалану җайланмасын Россия Федерациясе территориясендә газ бүлү челтәрләренә технологик ялгау өчен түләүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2000 елның 29 декабрендәге 1021 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең «Газдан файдалану җайланмасын газ бүлү челтәрләренә технологик ялгау өчен түләү күләмен һәм аның зурлыгын билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкаларын раслау турында» 2014 елның 28 апрелендәге 101-э/3 номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә газдан файдалану җайланмасын технологик ялгау буенча әлеге карар кушымтасына туры китереп түләү билгеләргә.
2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән түләү 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә газдан файдалану җайланмасын технологик ялгау буенча икътисадый яктан нигезләнгән түләү күләме 188,180 мең сум тәшкил итә.
4. «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең шушы карар кушымтасында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләрен тоташтырудан төшеп калучы керемнәрен 2224,804 мең сум күләмендә билгеләргә.
5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2017 № 6-186/тп карарына кушымта

## «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәренә газдан файдалану җайланмасын технологик ялгау өчен 2018 елга түләү

| № п/п | Мөрәҗәгать итүчеләрнең категориясе | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеге чикләреннән газ бүлү челтәрләренә кадәрге аралык | Технологик ялгау буенча түләү, сум. | |
|---|---|---|---|---|
| | | | НДС исәпкә алмыйча | НДС исәпкә алып<*> |
| 1. | Сәгатенә 5 куб. метрдан артмаган максималь газ сарыфы белән, мөрәҗәгать итүченең әлеге ноктага элегрәк тоташтырылган газдан файдалану җайланмасының газ сарыфын исәпкә алып (газдан эшкуарлык (коммерциячел) эшчәнлек максатларында файдалану нияте булмаган, башка мөрәҗәгать итүчеләр өчен), туры линия буенча үлчәнә торган эш басымы иң күбе 0,3 МПа булган проекты белән газдан файдалану җайланмасының заявка тапшырылган газ бүлү оешмасының газ бүлү челтәренә кадәрге аралык 200 метрдан артмау һәм чараларның бары тик газүткәргечләр – кертү җайланмасы (газ редукцияләү пунктларын урнаштырмыйча) төзүнең генә күздә тотылу шарты белән | 10 м кадәр (шуннан артмый) | 21 088,33 | 24 884,23 |
| | | 10 м озынрак, 20 м кадәр (шуннан артмый) | 31 632,49 | 37 326,34 |
| | | 20 м озынрак | 52 720,81 | 62 210,56 |
| 2. | Сәгатенә 15 куб. метрдан артмаган максималь газ сарыфы белән, мөрәҗәгать итүченең әлеге ноктага элегрәк тоташтырылган газдан файдалану җайланмасының газ сарыфын исәпкә алып (газдан | 200 м кадәр (шуннан артмый) | 52 720,81 | 62 210,56 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | эшкуарлык (коммерциячел) эшчәнлек максатларында файдалану нияте булган мөрәҗәгать итүчеләр өчен), туры линия буенча үлчәнә торган эш басымы иң күбе 0,3 МПа булган проекты белән газдан файдалану җайланмасының заявка тапшырылган газ бүлү оешмасының газ бүлү челтәренә кадәрге аралык 200 метрдан артмау һәм чараларның бары тик газүткәргечләр – кертү җайланмасы (газ редукцияләү пунктларын урнаштырмыйча) төзүнең генә күздә тотылу шарты белән | | | |

<*> Мөрәҗәгать итүчеләр – физик зат булган очракларда

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге